РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

«23» июнь 2020 ел № 11-54

Буа муниципаль район Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 9-24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23-25, 28 статьялары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Буа муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Буа муниципаль район Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 9-24 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегенең генераль планы»на (алга таба – Генплан) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Генпланның 220 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«220) Көнкүреш калдыкларын җыю, туплау, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне оештыру һәм гамәлгә ашыру калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасы нигезендә башкарыла. Каты коммуналь калдыкларны җыю, туплау һәм ташу Буа шәһәре полигонына, аннан соң чүп-чарны сортларга аеру станциясенә илтеп, башкарыла.»;

- Генпланның 385 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «385) Көнкүреш калдыкларын җыю, туплау, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне оештыру һәм гамәлгә ашыру калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасы нигезендә башкарыла. Каты коммуналь калдыкларны җыю, туплау һәм ташу Буа шәһәре полигонына, аннан соң чүп-чарны сортларга аеру станциясенә илтеп, башкарыла.»;

2. Гавами тыңлаулар үткәрүне таләп иткән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегенең Генераль планының эчтәлеге әлеге карар белән үзгәрми дип билгеләргә.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыгарга, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталында Интернетның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф. Еремеев